**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

04.02.2025 ел №158

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы карарын раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы карарын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуга Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны, аның дәүләт теркәвенә алынганнан соң, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Менделеевск районы, Татар Чаллысы авылы, Җиңү ур., 3А й..адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм hhttp://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru “Татар Чаллысы авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга
5. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын үтәү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
Советы рәисе Т.П. Кузнецова

Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының
2025 елның  4 февралендәге
158 номерлы карарына кушымта

1. Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 июнендәге 92 номерлы карары белән расланган Менделеевск муниципаль районы «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1) 5 статьяда:**

а) 1 **өлешнең 12** пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

б) түбәндәге эчтәлекле 20, 21 пункт өстәргә:

«20) үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, рөхсәтсез корылманы җимерү турында яисә аны федераль законнарда билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү, капиталь төзелеш объектларын җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турында карар кабул итү;

21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

2) 11 **статьяның 7** пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе белән» сүзләрен «территориаль комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 31 **статья**

а) 6 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.

б) 6 өлешнең 2 пунктының «б» пунктчасында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

в) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

г) 9 өлештә «Президент» сүзен «Башлык (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.

г) 10 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**4) 34 статьяда:**

а) 1 пунктның 14 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

б) 1 пунктның 28 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«28) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;»;

5) 41 **статьяның 1** пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасы өстәргә:
«10.1) аларга чит ил агенты статусын алу;»;

6) 44 **статьяда:**
а) 5 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.
6 ) 5 өлешнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**7) 50 статьяда:**
а) 1 пунктның 1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:
-хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә ала.
в) 1 пунктның 9 пунктчасының 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;
г) 1 өлешнең 7 пунктындагы 3 абзацны төшереп калдырырга.

8) 58 статьяның 3 **пунктында «һәм Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен** төшереп калдырырга.

9) 74 **статьяга** түбәндәге эчтәлекле **4 өлеш өстәргә:**
«4.Җирле үзидарә органнары муниципаль милектәге электр челтәре оешмасы яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасы яисә территориаль челтәр оешмасы системасында торучы электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашыралар»

10) 71 статьяны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**«71 статья. Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе**
1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:
1) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында тулы текстны рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; 2013 елның 17 декабрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык № ФС77-60244, яисә 2018 елның 28 сентябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән «Менделеевские яңалыклары» газетасында (ЭЛ № 77 - 73819 массакүләм мәгълүмат чарасы сыйфатында теркәлү турында таныклык ;
2) Менделеевск муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштыру.
3. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 10 көн эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка игълан ителә.
4. Районның салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.
5. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, имза салынган көннән үз көченә керә,
6. Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен игътибарга җиткерелә.